**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«11» 03 2025 ел Яр Чаллы № 756

«Муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә түләүсез бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2021 елның 26 октябрендәге 3783 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Җир кодексына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 34 статьясы 7 өлеше үз көчен югалтуын тану хакында» 2022 елның 07 октябрендәге 385-ФЗ номерлы Федераль закон, «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәмне киңәйтү максатында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 03 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә түләүсез бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2021 елның 26 октябрендәге 3783 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 3.3.3.4 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.3.3.4. Регламентның 3.3.3.1, 3.3.3.3 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлекләр булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда гамәлгә ашырыла.

Регламентның 3.3.3.1, 3.3.3.3 пунктларында күрсәтелгән һәм шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле аерым процедураларны үтәү кысаларында илкүләм пространство белешмәләре системасы эшчәнлеген тәэмин итүче федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.».

- 3.4.5 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.4.5. Регламентның 3.4.2, 3.4.4, 3.4.5 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлекләр булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын

кулланып, шул исәптән гариза регламентның 2.13 пункты нигезендә теркәлгән мизгелдән, автомат режимда гамәлгә ашырыла.

Регламентның 3.4.2, 3.4.4, 3.4.5 пунктларында күрсәтелгән һәм шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле аерым процедураларны үтәү кысаларында илкүләм пространство белешмәләре системасы эшчәнлеген тәэмин итүче федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.».

- 3.5.4 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.5.4. Регламентның 3.5.2-3.5.3 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлекләр булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда гамәлгә ашырыла.

Регламентның 3.5.2-3.5.3 пунктларында күрсәтелгән һәм шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле аерым процедураларны үтәү кысаларында илкүләм пространство белешмәләре системасы эшчәнлеген тәэмин итүче федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.

Регламентның 3.5 пунктында күрсәтелгән административ процедураларны башкаруның максималь вакыты 14 эш көнен тәшкил итә.».

- 3.6.2 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.6.2 Документлар бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазыйфаи зат: дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасы документациясен алып бару ярдәмче системасына (яки) шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итү мәгълүмат системасына муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында белешмәләрне теркәүне һәм кертүне тәэмин итә; гаризада күрсәтелгән ысул белән мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен органда яки КФҮдә алу мөмкинлеге хакында) хәбәр итә.

Процедураларны үтәү, техник мөмкинлекләр булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда гамәлгә ашырыла.

Процедураларны, шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле процедураларны үтәү кысаларында илкүләм пространство белешмәләре системасы эшчәнлеген тәэмин итүче федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.

Пунктта билгеләнгән административ процедуралар Органның вәкаләтле вазыйфаи заты (Орган) тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне (бирүдән баш тартуны) расլый торган документка имза салынган көннән алып бер эш көне эчендә башкарыла.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе

К.Р. Нәҗмиев